Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Иске Котыш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге составына керүче Иске Котыш торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17 октябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 17 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең Иске Котыш торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы), Иске Котыш торак пунктларында урам күрсәткечләрен һәм йорт номерларын бертөрле итеп ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) ясау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Иске Котыш торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Иске Котыш торак пунктындагы Байкал урамындагы 20 метрлы, Рус урамындагы 30 метрлы урам-юл челтәрен салу өчен 50-70 мм фракция вак ташы сатып алу), шулай ук (Себер, Октябрь, Фрунзе, Рус, Байкал урамнарындагы вак таш юл чокырларын ремонтлау.)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының **341** катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **181** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында **181** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге составына керүче Иске Котыш торак пунктларында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип таныйрга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан

инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы), Иске Котыш торак пунктларында урам күрсәткечләрен һәм йорт номерларын бертөрле итеп ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) ясау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Иске Котыш торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Иске Котыш торак пунктындагы Байкал урамындагы 20 метрлы, Рус урамындагы 30 метрлы урам-юл челтәрен салу өчен 50-70 мм фракция вак ташы сатып алу), шулай ук (Себер, Октябрь, Фрунзе, Рус, Байкал урамнарындагы вак таш юл чокырларын ремонтлау.)

3. Мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка игълан итәргә: Иске Котыш авылы, Свежухин ур., 33 нче йорт, Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми интернет сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге башлыгы А.К.Митякин